**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ӨТӘШКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2021 елның 29 апреле 30

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Өтәшкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләренә кермәгән Өтәшкә авыл җирлеге Советының 2021 елның 9 мартындагы 27 номерлы карары белән расланган яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Урман кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында»гы 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Өтәшкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Өтәшкә авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Өтәшкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән, Өтәшкә авыл җирлеге Советының 2021 елның 9 мартындагы 27 номерлы карары белән расланган яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 статьяның 2.3 пунктын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Яшел Үзән муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Өтәшкә авылы, Нагорная урамы, 99а (җирлек администрациясе бинасы), Өтәшкә авылы, Үзәк урамы, 40а (мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Өтәшкә авыл җирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе:** **А.А. Клопов**